**КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ**

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2016 ел, 23 июнь № 432

г. Казань

Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы карамагындагы һөнәри мәгариф учреждениеләре филиалларын бетерү турында

Квалификацияле эшчеләрне (хезмәткәрләрне), урта буын белгечләрен әзерләүнең сыйфатын күтәрү, сорау булган урта һөнәри белем бирү программаларын тормышка ашыру өчен шартлар тудыру, шулай ук хезмәт ресурсларыннан тагы да нәтиҗәлерәк файдалану максатларында Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгының түбәндәгеләрне бетерү турында тәкъдимен кабул итәргә:

«Бөгелмә аграр көллияте» дәүләт автоном һөнәри белем бирү учреждениесенең Ютазы муниципаль районында урнашкан филиалын (алга таба - Бөгелмә аграр көллияте филиалы);

«Апас аграр көллияте» дәүләт автоном һөнәри белем бирү учреждениесенең Кайбыч муниципаль районында урнашкан филиалын (алга таба - Апас аграр көллияте филиалы).

2. Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгына:

14 көн эчендә:

Бөгелмә аграр көллияте филиалының һәм Апас аграр көллияте филиалының бетерү комиссиясе составларын расларга;

Россия Федерациясе Граждан кодексы нигезендә Бөгелмә аграр көллияте филиалын һәм Апас аграр көллияте филиалын бетерү тәртибен һәм вакытын билгеләргә;

Бөгелмә аграр көллияте филиалын һәм Апас аграр көллияте филиалын бетерү турында карар кабул ителгәннән соң өч көн эчендә теркәүче органга хәбәр итәргә;

30 көн эчендә:

«Россия Федерациясендә Мәгариф турында» Россия Федерациясе Законы таләпләрен саклап, 2015/2016 уку елы тәмамланганнан соң Бөгелмә аграр көллияте филиалында квалификацияләнгән эшчеләр (хезмәткәрләр) әзерләү программалары буенча: «авыл хуҗалыгы җитештерүендә тракторчы-машинист» – 13 кеше, «пешекче, кондитер» – 20 кеше укучы студентларны «Бөгелмә аграр көллияте»

дәүләт автоном һөнәри белем бирү учреждениесенә күчерүне тәэмин итәргә;

Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгына «Апас аграр көллияте» дәүләт автоном һөнәри белем бирү учреждениесенә оператив идарә итү хокукында беркетелгән, Кайбыч муниципаль районында урнашкан, Кайбыч муниципаль районы милкенә бирелергә тиеш һәм «Бөгелмә аграр көллияте» дәүләт автоном һөнәри белем бирү учреждениесенә оператив идарә итү хокукында беркетелгән, Ютазы муниципаль районында урнашкан, Ютазы муниципаль районы милкенә бирелергә тиеш күчемсез мөлкәте исемлеген тапшырырга;

Бөгелмә аграр көллияте филиалын һәм Апас аграр көллияте филиалын бетерү буенча законнарда каралган бүтән чараларны гамәлгә ашырырга, шулай ук Россия Федерациясе Хезмәт кодексы нигезендә бетерү нәтиҗәсендә эштән чыгарылган хезмәткәрләргә гарантияләр һәм компенсацияләр бирүне тәэмин итәргә.

3. «Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты каршындагы Татарстан Республикасының икътисадый һәм социаль тикшеренүләр үзәге» дәүләт бюджет учреждениесенә Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы белән берлектә әлеге карарның 2, 3 пунктлары үтәлгәннән соң 30 көн эчендә Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2016 елга урта буын белгечләрне әзерләү программаларын тормышка ашыруга норматив чыгымнарны һәм Татарстан Республикасы дәүләт һөнәри белем бирү оешмаларын торак урыннар белән тәэмин итүгә норматив чыгымнарны раслау турында» 2015 ел, 16 октябрь, 776 нчы карарына күрсәтелгән карарны әлеге карарның 1 пунктына яраштыру өлешендә үзгәрешләр кертү хакында Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карары проектын эшләргә һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетына кертергә.

4. Бу карарның үтәлешен тикшерүдә тотуны Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгына йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры И.Ш.Халиков